**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Уразлы  авыл җирлеге Сатлыган авылында**
**гражданнарга үзара салым кертү турында**

21 нче ноябрь 2022 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сатлыган авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Салтыган авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, көндезге формада укучы студентлар) һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

* Сатлыган  авылы эчендәге юлларны ремонтлау(таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

* җәйге чорда территорияне чабу(ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

* Сатлыган  авылында юлларны тигезләү, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Салтыган авылы, Урта урамы, 1 нче йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Уразлы  авыл җирлеге башлыгы: М.Г.Хәмидуллин